БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«22» 02 2022 ел № 56

**«Татарстан Республикасы Балтач район Советы бүлекләре һәм муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи инструкцияләре турында нигезләмәләрне раслау хакында» 2015 елның 7 августындагы 150 номерлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башлыгы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Татарстан Республикасы Балтач район Советының җирле үзидарә органнары белән эшләү бүлеге исемен үзгәртү турында» 2022 елның 18 гыйнварындагы 102 номерлы һәм «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирлекләре белән кадрлар эше буенча аерым функцияләрне тапшыру турында» 2022 елның 18 гыйнварындагы 103 номерлы Балтач район Советы карарлары нигезендә, Тататарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Башлыгы карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Балтач район Советы бүлекләре һәм муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи инструкцияләре турында нигезләмәләрне раслау хакында» 2015 елның 7 августындагы 150 номерлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башлыгы карарының 2 пункты белән расланган Татарстан Республикасы Балтач район Советының җирле үзидарә органнары белән эшләү бүлеге турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Исемдә һәм 1.1 пунктта «җирле үзидарә органнары белән эшләү бүлеге» сүзтезмәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «кадрлар һәм җирле үзидарә органнары белән эшләү бүлеге».

1.2. 2.2 пунктка түбәндәге абзацны өстәргә:

«- Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнары белән килешүләр нигезендә Балтач район Советына тапшырылган кадрлар эше буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыра».

2. «Татарстан Республикасы Балтач район Советы бүлекләре һәм муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи инструкцияләре турында нигезләмәләрне раслау хакында» 2015 елның 7 августындагы 150 номерлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башлыгы карарының 6 һәм 9 пунктлары белән расланган җирле үзидарә органнары белән эшләү

бүлеге башлыгының һәм әйдәп баручы белгеченең вазыйфаи инструкцияләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. Исемдә һәм 1.2 пунктта «җирле үзидарә органнары белән эшләү бүлеге» сүзтезмәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «кадрлар һәм җирле үзидарә органнары белән эшләү бүлеге».

2.2. Җирле үзидарә органнары белән эшләү бүлеге башлыгының вазыйфаи инструкциясенең 3.7 пунктына түбәндәге абзацны өстәргә:

«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнары белән килешүләр нигезендә Балтач район Советына тапшырылган кадрлар эше буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыра».

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район Советы аппараты җитәкчесе Р.Х. Мөхәммәтҗановага йөкләргә.

Балтач муниципаль
районы башлыгы Р.Р. Нотфуллин